**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№01**
**09.01.2024**

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 9 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карамагындагы гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе»
муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәтнең бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. Көнбатыш зал хезмәтләре | | | 5 700,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 3 200,00 |
| 2 | Музыка белән алып бару (камера ансамбле) | 1 церемония | 1 500,00 |
| 3 | Котлау залы хезмәтләре | 1 церемония | 1 000,00 |
| 2. Көнчыгыш зал хезмәтләре | | | 4 100,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 2 900,00 |
| 2 | Музыка белән алып бару (соло) | 1 церемония | 1 200,00 |
| 3. Көньяк зал хезмәтләре | | | 2 600,00 |
| 1 | Тантаналы церемония оештыру һәм үткәрү | 1 церемония | 2 600,00 |
| 4. Церемониянең тантаналылыгын тәэмин итү буенча өстәмә хезмәтләр | | | |
| 1 | Музыка белән алып бару (вокал) | 1 церемония | 950,00 |
| 2 | Интерьерларны фото-видеога төшү өчен бирү | 1 пар | 300,00 |
| 3 | Церемонияне алып баручы хезмәте күрсәтү | 1 церемония | 700,00 |
| 4 | Гаиләләргә барып церемония үткәрү өчен яңа йолалар әзерләү | 1 церемония | 7 000,00 |
| 5 | Күгәрченнәр очыру йоласы | 1 пар | 800,00 |
| 6 | Роза таҗларыннан салют | 1 церемония | 300,00 |
| 7 | Гаилә дипломы тапшыру йоласы | 1 церемония | 600,00 |
| 8 | «Йозак – чиксез мәхәббәт символы» йоласы | 1 церемония | 650,00 |
| 9 | Тантаналар оештыру буенча хезмәтләрнең мәгълүматлар банкына мәгълүмат кертү | 1 айга / 1 төр хезмәт | 2 000,00 |
| 10 | Фото-видеога төшерү хезмәте (DVD-диск һәм 10 данәдән торган фотосурәтләр комплекты биреп) | 1 хезмәт | 3 500,00 |
| 11 | Индивидуаль юбилей тантаналары үткәрү | 1 церемония | 5 000,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева